ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.09.2026 1421

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы территориясендә террорчылык куркынычының төрле дәрәҗәләрен билгеләгәндә иминлекне тәэмин итү чаралары регламентын раслау турында» 2026 елның 1 сентябрендәге 1346 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Терроризмга каршы тору турында»гы 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Шәхеснең, җәмгыятьнең һәм дәүләтнең иминлеген тәэмин итү буенча чаралар күрүне күздә тота торган террорчылык куркынычы дәрәҗәләрен билгеләү тәртибе турында» 2012 елның 14 июнендәге 851 номерлы Указы нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы территориясендә террорчылык куркынычының төрле дәрәҗәләрен билгеләгәндә иминлекне тәэмин итү чаралары регламентын раслау турында» 2026 елның 1 сентябрендәге 1346 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы гражданлык яклау идарәсе» муниципаль казна учреждениесе директорына Россия Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм бәла-каза нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Баш идарәсенең кризис ситуацияләрендә идарә итү үзәге белән гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу яисә килеп чыгу куркынычы турында сигналларны вакытында алу һәм раслау өчен үзара хезмәттәшлекне тәэмин итәргә».

1.2. Регламентның 2.1 пунктындагы бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Балаларны һәм хезмәткәрләрне белем бирү оешмасы территориясенә кертүне туктатырга. Алабуга муниципаль районы белем бирү учреждениесе җитәкчесенең расланган боерыгы нигезендә, эш урынында булган хезмәткәрләр пилотсыз очучы аппаратлар һөҗүм итү һәм ракета куркынычлыгы вакытында халыкның гамәлләре турындагы регламентка таянып эш итә».

1.3. Регламентның 2.1 пунктындагы тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Куркынычсыз урында калырга, мөмкин булганча, якындагы яшерен урынга үтеп, урамга чыкмаска.».

1.4. Регламентның 3 бүлеген төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасары итеп йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы

ЕМСЭД
Республики Татарстан
СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП
Сертификат: 7C878CC2715BCC42F14A435C46E05934
Владелец: Томилин Андрей Александрович
Действителен с 27-08-2026 до 20-11-2027

А.А. Томилин